| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2021 Казан ш. № 210-27/кс-2021

2022 елга «Бөреле коммуналь челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм су агызуга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Бөреле коммуналь челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Бөреле коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ) өчен, әлеге карар кушымтасы нигезендә календарь буенча бүлеп, эчә торган суга һәм су агызуга тарифлар билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Бөреле коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.
4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
03.11.2021 № 210-27/кс-2021
карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Бөреле коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ өчен эчә торган суга һәм су агызуга 2022 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр |
| | Биектау муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Бөреле коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ* | 24,84 | 25,24 | 41,60 | 42,40 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге